РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ БОЛЬШЕШИНАРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
422054, Республика Татарстан,
Сабинский район,с.Большой Шинар,
ул. Кооперативная,дом 36
тел. (84362) 41-2-11

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ ШЫҢАР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422054, Татарстан Республикасы,
Саба районы,Олы Шыңар авылы,
Кооператив урамы, 36 йорт
тел. (84362) 41-2-11

e-mail: bshin.sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ
25.02.2022

КАРАР
№6

Татарстан Республикасы Саба муниципаль
районы Олы Шыңар авыл җирлеге Советының
2013 ел 14 октябрь 24нче номерлы карары
белән расланган «Татарстан Республикасы Саба муниципаль
районы Олы Шыңар авыл җирлеге территориясендә
урнашкан зиратларны карап тоту тәртибе турындагы
Нигезләмә»гә үзгәрешләр кертү хакында

Саба районы прокуратурасының 16.02.2002 ел, №02-08-02-/120-2022 протесты нигезендә, «Җирләү һәм җирләү эше турында»12.01.1996 ел, № 8-ФЗ Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге Советы карар җирә:

1.Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге Советының 2013 ел 14нче октябрь 24 нче номерлы карары белән расланган“ Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге территориясендә урнашкан зиратларны карап тоту тәртибе турындагы Нигезләмә”гә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 1.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1.2. җирләү урыннары булып, этик, санитар һәм экологик таләпләр нигезендә, аларда үлгән кешеләрнең мәетләрен (җәсәдләрен) күмү ечен корыла торган җир участоклары, үлгән кешеләрнең мәетләрен (җәсәдләрен) яндырганнан соң мәетләрне (җәсәдләрне) күмү өчен кайгы диварлары, үлгән кешеләрнең мәетләрен (җәсәдләрен) утка бирү ечен крематорийлар, шулай ук мәетләрне (җәсәдләрне) җирләү ечен билгеләнгән башка биналар һәм корылмалар тора. Җирләү урыннары мәдәни-тарихи әһәмияткә ия булган объектларга карый ала”.

1.2. Нигезләмәнең 1.5 пунктында “булырга мөмкин” сүзен “булу” сүзе белән алыштырырга.

1.3. Нигезләмәнең 1.6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1.6. җәмәгать зиратлары җирле үзидарә органнары карамагында. Җәмәгать зиратларының эшчәнлеге тәртибе җирле үзидарә органнары тарафыннан

билгеләнә. Авыл җирлекләре территорияләрендә җәмәгать зиратларының эшчәнлеге гражданнар тарафыннан мөстәкыйль гамәлгә ашырылырга мөмкин. Дин тотучы зиратлар бер диндәге мәрхүмнәрне җирләү өчен билгеләнгән. Дин тотучы зиратлар җирле үзидарә органнары карамагында булырга мөмкин. Дин тотучы зиратларның эшчәнлек тәртибе, тиешле дини берләшмәләр белән килешеп, җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнә. Авыл җирлекләре территорияләрендә дин тотучы зиратларның эшчәнлеге гражданнар тарафыннан мөстәкыйль гамәлгә ашырылырга мөмкин".

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча, Саба муниципаль районының Олы Шыңар авыл җирлегенең рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/shinar адресы буенча бастырып чыгарырга һәм җирлекнең мәгълүмати стендларында урнаштырырга.

Олы Шыңар авыл җирлеге башлыгы А.Г.Гарипов